**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ДӨРЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«28» октябрь, 2022 ел Иске Дөреш авылы № 14

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл жирлеге Иске Дөреш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Иске Дөреш авыл жирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 10 ноябренә 09:00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авылы Ленин, К.Маркс һәм Мәктәп урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенының беренче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Иске Дөреш авылы, Г.Тукай урамы, 21 йорт.

2. 2022 елның 10 ноябренә 10:00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авылы Г.Тукай һәм Яшьләр урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенының икенче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Иске Дөреш авылы, Г.Тукай урамы, 21 йорт.

3. Гражданнар жыенын үткәрү өчен, Иске Дөреш авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

4. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда яшәү урыны буенча Иске Дөреш авыл жирлеге Иске Дөреш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1. **Иске Дөреш авылында урам юлларын ремонтлау.**
2. **Урамнарны яктырту өчен электроматериаллар сатып алу.**

«ӘЙЕ» «ЮК».

4.1. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Иске Дөреш авыл жирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә.

5. Халык жыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл жирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны авыл жирлегенең рәсми стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иске Дөреш авыл жирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков